«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
История населенных пунктов (деревень, городов) Горной стороны.

Фәнни – тикшеренү эше
Тема: “Авылым – тарихы”

Хезмәтне башкаручы:
«ТР ЗМР 16 УГБМ»
7 а сыйныф укучысы
Ашерапова Азалия
Җитәкчесе:
технология укытучысы
Бикмөхәммәтова Сөмәя
Гумәр кызы

**Яшел Үзән 2020**

Эчтәлек

1. Кереш өлеше.

2. Төп өлеш:

2.1. Авылның килеп чыгышы;

2.2. Авыл җирлеге;

2.3. Авыл мәктәбе- балалар бакчасы;

2.4. Авылыбыз мәчете;

2.5. Авылның чишмәләре, урманнары.

3. Йомгаклау.

4. Кулланылган әдәбият.

### *1. Кереш өлеше.*

**Максат:**

Үз авылыңның килеп чыгышын һәм тарихын белү.

**Бурыч:**

Туган авылымның тарихын өйрәнү

Өлкән яшьтәге авыл кешеләре аралашып мәгүлүмат җыю

Туган авыл турындагы белемнәрне киңәйтү.

**Проектның актуальлеге**:

Туган авыл һәр кеше тормышында аерым бер үзенчәлекле, кадерле урын алып тора. Җиде буынга кадәр нәселеңне
белү, туып-үскән җиреңнең үткәне белән кызыксыну – һәркемнең изге бурычы дип санаганнар безнең бабаларыбыз һәм аны васыять итеп буыннан – буынга тапшырганнар.

Үткәнен, тарихын белмәгән кешенең бүгенгесе һәм киләчәге юк. Тарих бит ул олы диңгез кебек вак-вак тамчылардан, күлләрдән җыела, шул "тамчылар"ярдәмендә безнең үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез формалаша. Ләкин кызганыч, барлык фактлар да теркәлеп бара алмый, кайбер вакыйгалар, язылып бармау сәбәпле, вакытлар узу белән онытыла, хәтердән җуела. Шуның нәтиҗәсендә тарихыбызга зыян килә, аның бер чите кителә.

Бу хезмәтемнең максаты – туган ягым тарихына кагылышлы кайбер тарихи документларга, халыктан язып алынган мәгълүматларга таянып, авылымның тарихын яктырту,борынгы бабаларым яшәгән чорны өйрәнү. Бу хезмәтемне язганда төрле авырлыклар белән дә очрашырга туры килде, чөнки күп нәрсә онытылган, югалган һәм истәлекләр күбесенчә борынгы бабаларыбызның балалары сөйләгәннәренән тупланды. Шулай ук мәктәп

архивлары белән танышу, китапханәдә утыру да зур нәтиҗә бирде.Үземне кызыксындырган сорауларга җавап табарга теләп өстәмә чыганаклар эзләдем, тарихчыларның хезмәтләренә мөрәҗәгать иттем. Аның халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, яшәешен белергә кирәк. Шул вакытта гына кешедә авылына карата зур ихтирам һәм мәхәббәт уяна.

## *2.Төп өлеш.*

### *2.1. Авылның килеп чыгышы.*




Мамадыш-Әкил авылы 1500 нче елларда барлыкка килгән.

Моннан башка шул тирәдә тагын өч-дүрт авыл бар. Ул авыллар бер кешенең балаларыннан килеп чыкканнар. Җәмид исемле кеше үзенең биш баласы, бер сеңлесе белән Болгардан килеп шушы җиргә төпләнгән.

Беренче улы- Мәмәткал исемле булган. Ул төпләнгән авылга- Мамадыш-Әкил дип исем кушылган.

Икенче улы Тәүгилде исемле, ул төпләнгән авылга Танай исеме бирелгән.

Өченче улы- Габделхаликъ исемле, ул төпләнгән авылга Багай исеме бирелгән. Ул урыс авылы.

Дүртенче улы- Арыслан исемле, ул төпләнгән авылга Арысланово исеме бирелгән. Ул да урыс авылы.

Бишенче улының исеме билгесез, ә ул төпләнгән авылны Гордеево

дигәннәр. Ул да урыс авылы.

Сеңлесенең исеме Сагындык. Хәзерге Сатлыган авылы аннан калгандыр. Татарча исеме- Ышналы башы.

Мамадыш – Әкил 1920 нче елга кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1927нче елның 14 февраленнән Норлат-Ачасыр, 1927нче елның 1 августыннан Норлат районы, ә 1963 нче елның 1нче феврвленнән хәзерге вакытка кадәр Яшел Үзән районына керә. Авыл Яшел Үзән шәһәреннән 47 километр көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Республикасы белән чиктәш урнашкан.

1930 нчы елда “Ленин исеме”ндәге колхоз оеша. Ул елдан ел үсеп, баеп бара. Алдынгылар исеменә чыга. Шулай итеп 2002нче елга кадәр эшли, ә 2002 нче елдан “Красный Восток” килә һәм колхозларның бетүенә китерә.

Халыкның иң төп шөгыле- кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Җәй көннәрендә кырларда яшелчә үстергәннәр.

***2.2.Авыл җирлеге.***



Мамадыш-Әкил авыл җирлегенә дүрт авыл керә: Мамадыш-Әкил, Татар Танае, Рус Танае һәм Панау авыллары керә. Авылларның икесе- Панау һәм Рус Танае- рус авыллары, ә Мамадыш-Әкил белән Татар Танае- татар авыллары. Дүрт авыл үзара тату һәм дус яшиләр. Авыл җирләге рәисе халыкка кулдан килгәнчә ярдәм итеп тора. Авылыбызга асфальт юл салдырды.

2019нчы елда авылыбызга яңа Акушер-Фельдшерлык пункты салынды. Анда авыл халкына беренче ярдәм күрсәтелә.   Авылыбызда мәдәният йорты, китапханә һәм ике кибет эшли.

Бөек Ватан сугышына авылыбыздан 400 кеше киткән, шуларның 210сы кире авылыбызга әйләнеп кайтмаган. Исән калганнары да күп кенә тән җәрәхәте алып кайткан. Авылыбыз уртасында үлеп калучылар истәлегенә хәтер тактасы куелган. Һәр ел анда искә алу кичәсе уздырыла.




*2.3.Авыл мәктәбе- балалар бакчасы.*

Безнең авылда башта 9 еллык мәктәп булган. Анда күрше авыллардан килеп укыганнар, ә 10-11нче сыйныфларны Әҗәлгә яки Норлатка барып укыганнар. 2008 нче елда 9 еллык мәктәп бетә, 4 еллыкка кала. Ул да озак эшләми, 2011нче елда ябыла. Балалар күрше Танай авылына йөреп укый башлыйлар. Шул елның сентябрь аенда мәктәп урынына балалар бакчасы ачыла. Балалар бакчасы бүгенге көнгәчә эшли.



***2.4.Авылыбыз мәчете.***



Авылыбызда мәчет авыл оешканнан бирле булган. Анда кызлар һәм малайлар өчен аерым мәдрәсә булган. Авыл халкы дини һәм Аллаһа Тагәләгә ышанып яшәгән. 1937-1938нче елларда мәчетнең манарасын кисеп төшергәннәр. Халык үз динен югалтмый, мәчет беткәч кеше йортларына җыелып намаз укыганнар. 1995нче елда авылыбызда яңадан мәчет төзелә. Хәзерге көнгә кадәр авыл өстендә Азан тавышы яңгырый. Хатын кызлар өчен мәдрәсә эшли, алар анда белем алырга бик теләп йөриләр.

### *2.5.Авылның чишмәләре, урманнары.*

Безнең авыл чишмә һәм урманнарга бик бай. Алар авылыбызның һәр ягында урнашкан.

Авылга керер алдыннан безне Туйралык чишмәсе һәм урманы каршы ала. Ул урманда Туйра агачы бик күп үскән. Агач үсеп картайгач Имән агачына әйләнгән. Халык урманны чистартып торган. Урман астыннан чыккан чишмәгә “Туйралык” дип исем биргәннәр. Аны хәзер дә чистартып торалар, тирә-ягын бура белән тотып алганнар. Чишмәдән су ала торган урынга матур самовар куйдылар. Аның суы чиста һәм тәмле. Шәһәр кешеләре дә суны шуннан алып китә.





Авылыбызның икенче ягында ике чишмә бар. Алар бер-берсеннән ерак түгел. Берсе Кизләү, ә икенчесе Гайнулла чишмәсе дип атала. Авыл халкы чишмәләрне карап, чистартып тора. Кизләү чишмәсенең йомшак тәмле суы авыл кешесенең өенә кергән. Чишмәләр өстендә Күгәй тавы һәм урманы бар. Ул таудан урман аша Норлатка йөргәннәр.


(Гайнулла чишмәсе)
(Кизләү чишмәсе)

Авылыбыз кырыеннан Гөбнә елгасы ага. Ул елга Багай белән безнең авылны аерып тора. Елга аша күпер бар, күрше авыллар шул күпердән чыгып безгә базарга килгәннәр.

Авылыбызда ике күл бар: Көмеш Күл һәм Әмәк күле. Җәе буе каз-үрдәкләр шунда коеналар. Кышка кергәч чанада һәм тимераякларда шуабыз.

## *3. Йомгаклау.*

Туган авыл тарихын, анда яшәүче халыкның тормышын, килеп чыгышын өйрәнеп мондый нәтиҗәгә килдем. Һәр кеше үзенең туган авылының тарихын белсә, ул аны алга таба да саклар һәм буыннан буынга күчерер. Мин бу проект эшен әзерләп авылым турында купне белдем. Тик шулай да, монда гына тукталып калырга теләмим. Киләчәктә авылымның күренекле шәһесләре турында да материаллар туплап бу хезмәтемне дәвам итәргә уйлыйм.

## ***4.Кулланылган әдәбият.***


1. “Касыйм шәйех – газиз”, ( 2008 ел китабыннан 20нче бит);
2. “Шамил абый язмалары”ннан.